**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Иске Үтәмеш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге составына керүче
Урманасты Үтәмеш торак пунктында

**18 октябрь 2024 ел** **№13**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Урманасты Үтәмеш торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2025 елда Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлегенең Урманасты Үтәмеш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган һәм даими яшәүче кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, шулай ук мобилизацияләнгән гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Урманасты Үтәмеш торак пунктларында **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне)башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- **урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен**, **трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен башка билгеләнештәге җиһазларны ремонтлау** (Урманасты Үтәмеш торак пунктында урамнарны яктырту яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);
- **җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү** Урманасты Үтәмеш торак пунктындагы чишмәләрне ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- **су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә**

**торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (Урманасты Үтәмеш торак пунктында, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

2. Әлеге карарны Урманасты Үтәмеш, Совет урамы, 12а йорт адресы буенча мәгълүмати стендларда һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Утәмеш авыл җирлегенең Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.С.Мингулов